# КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Городище торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2023 елның 17 ноябре № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 17 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге Городище торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белеем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире 600 сумкүләмендә 2024 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнар, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баланың ата-аналары түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Городище авылында Октябрь урамындагы юлны ремонтлау (подряд килешүе буенча эш өчен түләү).

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Городище торак пунктында гражданнар җыены карары 02.11.2021нче елның № 4 нигезендә янгын гидрантларын урнаштыруга (башкарылган эшләр өчен килешү буенча түләү) 282260,02 сум күләмендә җыелган гражданнарныц үзара салым акчаларын Городище авылында Октябрь урамындагы юлны ремонтлауга җибәрергә (подряд килешүе буенча эш өчен түләү)

ӘЙЕ ЮК».

Мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 349 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 178 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 178 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Городище торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге Городище торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире 600 сум күләмендә 2024 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнар, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баланың ата-аналары түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Городище авылында Октябрь урамындагы юлны ремонтлау (подряд килешүе буенча эш өчен түләү).

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Городище торак пунктында гражданнар җыены карары 02.11.2021нче елның № 4 нигезендә янгын гидрантларын урнаштыруга (башкарылган эшләр өчен килешү буенча түләү) 282260,02 сум күләмендә җыелган гражданнарның үзара салым акчаларын Городище авылында Октябрь урамындагы юлны ремонтлауга җибәрергә (подряд килешүе буенча эш өчен түләү)

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Кармалы авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

ИНН 1630003122 «Совет Кармалинского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»

Гражданнар җыенында рәислекитүче,
Кармалы авыл җирлеге башлыгы А.Д. Кубышкин